КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 23 декабрь г.Казань № 1271

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары төзү, аларны реконструкцияләү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 29 апрель, 350 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары төзүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда милекчеләргә

китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары төзү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 29 апрель, 350 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 17 август, 697 нче; 2020 ел, 12 ноябрь, 1018 нче; 2021 ел, 17 май, 341 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары, метрополитен станцияләре төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары, метрополитен станцияләре төзү, аларны реконструкцияләү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары, метрополитен станцияләре төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары, метрополитен станцияләре төзү, аларны реконструкцияләү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.»;

әлеге карар белән расланган Җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары төзү, аларны реконструкцияләү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары, метрополитен станцияләре төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары, метрополитен станцияләре төзү, аларны реконструкцияләү

буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары, метрополитен станцияләре төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары, метрополитен станцияләре төзү, аларны реконструкцияләү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге (алга таба – муниципаль берәмлек) бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба – шул ук эзлеклелектә чаралар, башка бюджетара трансфертлар) бирү кагыйдәләрен, максатларын һәм шартларын билгели.»;

5 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрүгә һәм автомобиль юллары, метрополитен станцияләре төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыяннарны каплауга башка бюджетара трансфертлар бирелгән очракта – җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм автомобиль юллары, метрополитен станцияләре төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыяннарны каплау буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү өчен муниципаль контрактларның расланган күчермәләрен;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җир кишәрлекләрен, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын алуга, шулай ук автомобиль юллары, метрополитен станцияләре төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыяннарны каплауга башка бюджетара трансфертлар бирелгән очракта – җир кишәрлекләрен, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын алу һәм автомобиль юллары, метрополитен станцияләре төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыяннарны каплау турындагы килешүләрнең расланган күчермәләре яки законлы көчкә кергән суд актларының расланган күчермәләрен.»;

9 пунктта:

алтынчы абзацта «автомобиль юллары» сүзләреннән соң «, метрополитен станцияләре» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта «автомобиль юллары» сүзләреннән соң «, метрополитен станцияләре» сүзләрен өстәргә;

сигезенче абзацта «автомобиль юллары» сүзләреннән соң «, метрополитен станцияләре» сүзләрен өстәргә;

10 пунктның беренче абзацында «автомобиль юллары» сүзләреннән соң «, метрополитен станцияләре» сүзләрен өстәргә;

16 пунктның беренче абзацында «автомобиль юллары» сүзләреннән соң «, метрополитен станцияләре» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин